ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 31 » август 2018 ел** **№ 737**

**Об организации питания учащихся в общеобразовательных учреждениях Арского муниципального района на 2018-2019 учебный год**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, балаларны баланслы кайнар ризык белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр күләмнәре турында» 2017 елның 8 сентябрендәге 641 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның балансланган кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:

1.1 2018 елның 1 сентябреннән Арча муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүне һәр уку көненә 7 сум 10 тиен, ата-аналар түләве һәм мәктәп яны участогыннан кергән керемнәр белән тәэмин итүне оештырырга.

1.2. 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган,ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен республика субсидиясе исәбенә 7 сум 10 тиен, 15 сум күләмендә кайнар аш оештырырга.

1.3. Үз составында 4 һәм аннан да күбрәк балалары, ятим балалары, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар булган гаиләләр өчен кайнар ризык белән тәэмин итүне түләүсез оештыру рәвешендә социаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында локаль-хокукый актны кабул итәргә.

1.4. Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчаларны максатчан куллануны һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә, мәктәп яны участоклары продукциясе исәбенә мәктәп ашлары ассортиментын баету эшен көчәйтергә.

1.5. Витаминнар, микронутриентлар белән баетылган төп туклану матдәләрен карап тоту буенча балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

1.6. Гомуми белем бирү учреждениеләренә продуктларның өзлексез килүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

2. Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасына 2018, 2019 елларга Арча муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә гомуми белем бирү учреждениеләренең барлык укучылары өчен уку вакытында кайнар туклануны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

3. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының»2017-2018 уку елына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында "2017 ел, 12 сентябрь, 1037 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИСО) куллану юлы белән һәм ЕГИСО операторы билгеләгән форматларга туры китереп мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

5 Социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИСО) куллану юлы белән һәм ЕГИСО операторы билгеләгән форматларга туры китереп мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И.Гарифҗновка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин